Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXIX-9**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 19 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 апрелендәге 6 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 4 маддәдә:

– 5 пунктның 3 абзацына түбәндәге эчтәлектәге ярдәмче абзацны өстәргә:

«капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтенә таләпләр;»;

– түбәндәге эчтәлектәге 12 пункт белән тулыландырырга:

«12. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтенә таләпләр капиталь төзелеш объектының күләм-пространство (киңлек), архитектура-

стилистик һәм башка сыйфатламаларына, әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган таләпләрне үз эченә ала.»;

– 12 нче пунктны тиңдәшле рәвештә 13 нче пункт дип санарга;

1.2) 15 маддәнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт өстәргә:

«1.1 Җир кишәрлекләренең хокук ияләре рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәтнамә сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы, әгәр мондый тайпылу рөхсәт ителгән төзелешнең бер яки берничә чик параметрларын бер тапкыр үзгәртү, конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү максатларында кирәк булса, ун проценттан артык түгел.»;

1.2) 16 маддәнең 1 пунктында «капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү» сүзләреннән соң «мондый рөхсәтнамә бирү турында гариза килгән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә һәм» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3) 25 маддәсенең 2 өлешендәге 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4) җир кишәрлегендә ярдәмче куллану төзелмәләре һәм корылмалары төзү, аларны кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.;»;

1.3) 26 маддәнең 7 пунктының 4 абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

27 маддәдә:

– 5 пунктның 3 пунктчасында «проект» сүзен «Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15 өлеше нигезендә расланган проект» сүзләренә алмаштырырга;

– 5 пунктның 4 пунктчасында «проект» сүзен «Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсендәге 15 өлеше нигезендә расланган проект» сүзләренә алмаштырырга;

1.4) - 5 пунктның 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 4.1, 4.2 пунктчалар өстәргә:

«4.1) проект документациясенә кертелә торган проект документациясен әзерләүче затлар әгъзалыгына нигезләнгән, үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан һәм әлеге зат Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектлауны оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган зат тарафыннан тәкъдим ителгән үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау проект документациясенә Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 өлеше нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта;

4.2) проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау, ул башкарма хакимият органы яисә проект документациясенә экспертиза уздырган оешма тарафыннан бирелгән, шәһәр төзелеше кодексының 49

маддәсендәге 3.9 өлеше нигезендә эксперт озата бару (бергә теркәп җибәрү) барышында проект документациясенә үзгәрешләр кертелгән очракта;

– 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«- әгәр мондый килешү шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү;»;

– 5 пунктның 6 пунктчасында «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсендәге 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан, блокланган төзелештәге барлык йортларның да хокук ияләренең бер рәттә төзекләндерелгән очракта ризалыгыннан гайре,» сүзләрен өстәргә.;

9 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« төзелеш этабы» - капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү, әгәр мондый объект эксплуатациягә кертелергә һәм автоном рәвештә эксплуатацияләнергә мөмкин булса, бер җир кишәрлегендә төзелергә, реконструкциягә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары арасыннан төзү яисә реконструкцияләү (ягъни бу җир кишәрлегендә башка капиталь төзелеш объектларын төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә), капиталь төзелеш объектын төзү яисә реконструкцияләү, ул автоном файдалануга кертелергә һәм эксплуатацияләнергә мөмкин (ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә), шулай ук капиталь төзелеш объектын урнаштыру (капиталь төзелеш объекты өлеше), биналарны, корылмаларны сүтү, инженерлык коммуникацияләрен яңадан кору (күчерү), вакытлы биналар һәм корылмалар төзү, урман кисү һәм башка эшләр өчен кирәкле җир кишәрлекләренә ия булу һәм алардан файдалану хокукларын рәсмиләштерүне үз эченә алган төзелеш территориясен әзерләү эшләре комплексы.»;

1.5) 28 маддәдә:

– 5 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә» сүзләрен «әлеге Кодекс нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.8 һәм 3.9 өлешләрендә каралган тәртиптә.» сүзләренә алмаштырырга;

– 7 пунктта «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен өстәргә;

– 10 нчы пунктның 1 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.6) 29 маддәдә:

– 3 пунктның 2, 4, 6 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

– 3 пунктның 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документациясе (шул исәптән эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 маддәсендәге 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документациясенең бер өлеше булган үзгәрешләрне исәпкә алып) таләпләренә туры килүе турында Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54

маддәсендәге 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта), Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 54 маддәсендәге 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган федераль башкарма хакимият федераль органының федераль дәүләт экологик күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкилнең бәяләмәсе (алга таба - федераль дәүләт экология күзәтчелеге органы);»;

– 4 пунктта «ун көн эчендә» сүзләрен «биш эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

-5 пунктның 4,5 абзацында «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 маддәсендәге 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан гайре» сүзләрен өстәргә;

1.7) 30 маддәдә:

– 2 пунктның 2 абзацына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«-территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү.»;

– 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«-Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы яисә юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат);

- Татарстан Республикасы төзегән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзегән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы төзегән юридик зат йә территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы кабул иткән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче зат тарафыннан;.»;

– 6 пунктта «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

- 12 пунктта «ике айдан да ким булмаган һәм дүрт айдан да артык булмаган» сүзләрен «бер айдан да артык булмаган» сүзләре белән алыштырырга;

1.8) 32 маддәнең 2 пунктында «зона » сүзеннән соң « җир кишәрлеге чикләре җир законнарына ярашлы рәвештә территориаль зоналар чикләрен кисеп чыга ала» дигән сүзләр белән тулыландырырга, өченче һәм дүртенче җөмләләрне төшереп калдырырга;

1.2) 36 маддәдә:

– 7 пунктның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшәү тирәлеге булган елганың, күлнең, сусаклагычның яр буе саклау полосасы киңлеге, яңадан житештерү урыннары, уылдык чәчү, көрәйтү, аеруча кыйммәтле су биологик ресурсларының миграция юллары (күрсәткечләрнең берсе булган очракта) һәм (яисә) табу (аулау) өчен файдаланыла торган су биологик

ресурсларының һәм аларның яшәү тирәлегенең мондый төрләрен саклап калу, ярларның текәлегенә бәйсез рәвештә, ике йөз метр күләмендә билгеләнә.»;.

-7 пунктның 18 абзацында «туфракның уңдырышлылыгын җайга салу» сүзләрен «туфракның уңдырышлылыгын арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

-7 пунктның 21 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-пестицидлар һәм агрохимикатлар саклау (яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш диңгез портлары территорияләрендә махсуслаштырылган саклагычларда агрохимикатлар саклаудан гайре), пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану;»;

7 пунктның 32 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-автозаправка станцияләрен, ягулык-майлау материаллары складларын (автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә, шул исәптән кече суднолар кую өчен базалар (корылмалар) , федераль иминлек хезмәте органнары объектларында урнаштырылган очраклардан гайре), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен кулланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләрен төзү һәм реконструкцияләү, транспорт чараларын юуны гамәлгә ашыру;».

- 8 пунктның 35 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-нефть һәм нефть продуктларының су объектларын һәм алар янындагы территорияләрне саклауны һәм әйләнә-тирә мохиткә башка тискәре йогынтыны тәэмин итә торган корылмалар.»;

– 11 пунктның 21 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов